Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Шигали авыл җирлеге Советының ундүртенче утырышы

Шигали авыл җирлеге советы утырышы
**КАРАРЫ**

28 март 2019 ел № 37

«Физик затлар милкенә салым турында» Шигали авыл җирлеге Советының 2014 елның 20 ноябрендәге 10 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге нигезендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шигали авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

Шигали авыл җирлеге Советының 2014 елның 20 ноябрендәге «Физик затларның милкенә салым турында» гы 10 номерлы карарына (Советның 2015 елның 15 июнендәге 11 номерлы, 2016 елның 14 ноябрендәге 16 номерлы, 2018 елның 25 маендагы 11 номерлы, 2018 елның 30 ноябрендәге 26 номерлы карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. Түбәндәге эчтәлекле 4 һәм 5 пункт өстәргә:

«4. Физик затлар милкенә салым түләүдән азат итү:

4.1. 18 яшькә кадәрге дүрт һәм аннан да күбрәк балалары булган граҗданнар;

4.2. әлеге пунктның 4.1 пунктчасында күрсәтелгән гражданнар балалары

5. Салым ташламасы салым салу объектларының түбәндәге төрләренә карата бирелә:

1) фатирлар (фатирның бер өлеше, бүлмә) яки торак йортның бер өлеше (торак йортның бер өлеше);

2) гараж яки машина-урыннар.».

Салым ташламасына хокукы булган зат салым органы үзенең теләге белән салым ташламалары бирү турында гариза тапшыра, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслаучы документлар бирергә хокуклы.

Салым ташламасы Шигали авыл җирлеге территориясендә даими яшәүче (билгеләнгән тәртиптә теркәлгән) салым түләүчеләр тарафыннан салым түләүченең милкендә булган һәм эшмәкәрлек эшчәнлегендә файдаланылмый торган салым салу объектына карата салым суммасы түләнергә тиешле күләмдә бирелә.

Ташламага хокукы булган зат салым органына ташламалар бирү турында гариза һәм Россия Федерациясе Салым кодексы белән билгеләнгән срокларда салым ташламасына хокукын раслаучы документлар тапшыра.».

2. 4 һәм 5 пунктлары 6 һәм 7 пунктлары дип санарга.

3. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») район газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2018 елның 1 гыйнварыннан физик затлар милкенә салым исәпләү белән бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Шигали авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Гайфуллин